**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

06.03.2026

№ 104

**Татарстан Республикасында Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешү буенча чаралар координаторлары һәм Татарстан Республикасында Россия Федерациясе субъектлары югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләренең үтәлеше өчен җаваплы республика башкарма хакимият органнары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешү буенча чаралар координаторлары һәм Татарстан Республикасында Россия Федерациясе субъектлары югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләренең үтәлеше өчен җаваплы республика башкарма хакимият органнары исемлеген раслау турында» 2021 елның 19 мартындагы 116 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Президентының 2021 елның 2 июнендәге 176 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 11 маендагы 164 номерлы һәм 2025 елның 14 мартындагы 129 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

14 пунктның «Татарстан Республикасында Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечен үтәү өчен җаваплы республика башкарма хакимият органы» графасына «; Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты» сүзләрен өстәргә;

19 пунктның «Татарстан Республикасында Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектлары башкарма органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечен үтәү өчен җаваплы республика башкарма хакимият органы» графасына «; Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты» сүзләрен өстәргә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ